ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларын төзү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 12 пункты һәм 86 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге комитетларын төзергә:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты;

5) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты;

6) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты;

7) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты;

8) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты.

2. Комитетлар түбәндәге төп юнәлешләр буенча закон проектларын эшләүне, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына керә торган мәсьәләләрне алдан карауны һәм әзерләүне, законнарның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы норматив хокукый актларының үтәлүен һәм башкарылуын гамәлгә ашыралар дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты:

1) Татарстан Республикасының конституциячел корылышы нигезләре;

2) федератив корылыш мәсьәләләре;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятен оештыру;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка комитетлары каравына кертелгән мәсьәләләрдән тыш, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын һәм башка дәүләт органнарын оештыру мәсьәләләре;

5) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, аның органнарының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының статусы;

6) җирле үзидарә, моңа җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка комитетлары карамагындагы мәсьәләләр буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү керми;

7) сайлаулар һәм референдумнар турында законнар;

8) Татарстан Республикасы дәүләт символлары;

9) Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре;

10) дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт;

11) Татарстан Республикасының административ-территориаль корылышы;

12) парламентара хезмәттәшлек;

13) комитет каравына кертелгән башка мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты:

1) бюджет корылышы һәм бюджет процессы;

2) бюджетара җайга салу;

3) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты һәм аның үтәлеше турында хисап;

4) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты һәм аның үтәлеше турында хисап;

5) Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлешенә контроль;

6) салымнар һәм җыемнар турында законнар;

7) Татарстан Республикасы Хисап палатасын төзү һәм аның эшчәнлеге;

8) комитет каравына кертелгән башка мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты:

1) Татарстан Республикасы икътисадын дәүләт җайга салуы нигезләре, Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү һәм стратегик планлаштыру мәсьәләләре;

2) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразын карау;

3) Татарстан Республикасы инвестиция сәясәте;

4) Татарстан Республикасы сәнәгать сәясәте;

5) инновация эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте;

6) мөлкәт мөнәсәбәтләре, Татарстан Республикасы милке белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте, хосусыйлаштыру;

7) Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеген, шул исәптән кече һәм урта бизнесны үстерү;

8) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге мәсьәләләре;

9) хуҗалык итү субъектлары эшчәнлеге мәсьәләләре;

10) дәүләт сатып-алулары, дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар ташу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү;

11) сәүдә эшчәнлеге (азык-төлек мәсьәләләреннән тыш);

12) бәяләр сәясәте;

13) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә кулланучыларның тиешле сыйфатка ия товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу хокукларын яклау;

14) мәгълүматлаштыру, элемтә;

15) туристлык эшчәнлеге, реклама;

16) комитет каравына кертелгән башка мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты:

1) торак законнары (торак өлкәсендә социаль ярдәм чараларын бирү мәсьәләләреннән тыш);

2) Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше һәм төзелеш мәсьәләләре;

3) Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре;

4) энергетика, нефть-газ тармагы һәм башка ягулык ресурслары өлкәсендә дәүләт җайга салуы;

5) энергияне сак тоту;

6) транспорт, юл хуҗалыгы һәм логистика мәсьәләләре;

7) тариф сәясәте;

8) коммуникация чараларының перспектив юнәлешләрен үстерү;

9) комитет каравына кертелгән башка мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты:

1) табигать ресурслары һәм табигатьтән файдалану, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдалану, урманнан файдалану һәм урманнарны торгызу, судан файдалану;

2) җир турында законнар;

3) әйләнә-тирә мохитне саклау, шул исәптән су ресурсларын, җир асты байлыкларын, туфракны, урманнарны, атмосфера һавасын, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклау; махсус сакланылучы табигать территорияләре;

4) халыкның санитария-эпидемиология иминлеге;

5) халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау;

6) экологик экспертиза;

7) аучылык һәм аучылык хуҗалыклары, балыкчылык хуҗалыклары;

8) җитештерү һәм куллану калдыклары;

9) халыкка экологик белем һәм тәрбия бирү;

10) агросәнәгать комплексы;

11) азык-төлек сәясәте;

12) коммерциячел булмаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтләре;

13) ветеринария эше;

14) комитет каравына кертелгән башка мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты:

1) Татарстан Республикасы территориясендә законлылык, хокук тәртибе, иҗтимагый иминлек тәэмин итүнең закон чыгару аспектлары, шул исәптән күрсәтелгән өлкәләрдә гражданнар хокукларын яклау;

2) коррупциягә каршы көрәш буенча закон чыгару аспектлары;

3) хокук бозуларны профилактикалау һәм иҗтимагый тәртипне саклау;

4) суд һәм хокук саклау органнары кадрлары;

5) Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары, суд бергәлеге органнары, адвокатура, нотариат эшчәнлеге мәсьәләләре;

6) Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге мәсьәләләре;

7) административ хокук бозулар турында законнар;

8) гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе;

9) янгын куркынычсызлыгы һәм һәлакәттән коткару хезмәтләренең һәм һәлакәттән коткару формированиеләренең эшчәнлеге;

10) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты мәсьәләләре;

11) граждан җәмгыяте институтларының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара эшчәнлеген үстерү;

12) миграция сәясәте;

13) хокукый культураны формалаштыруга ярдәм итү;

14) Татарстан Республикасының хокукый системасын үстерү һәм законнарны системалаштыру мәсьәләләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында чираттагы елга закон проекты эшенең якынча планы проектын төзү;

15) комитет каравына кертелгән башка мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты:

1) сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт;

2) хезмәт мөнәсәбәтләре, халыкны эш белән тәэмин итү, хезмәтне саклау;

3) гражданнарның аерым категорияләрен социаль яклау һәм социаль тәэмин итү (дәүләт граждан хезмәткәрләрен, муниципаль хезмәткәрләрне һәм дәүләт һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны пенсия белән тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрдән тыш);

4) гаиләне, аналарны, аталарны һәм балаларны саклау;

5) Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге мәсьәләләре;

6) демографик һәм яшьләр сәясәте;

7) комитет каравына кертелгән башка мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты:

1) мәгариф;

2) мәдәният һәм сәнгать;

3) Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклап калу һәм үстерү;

4) татар халкының һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләренең милли үзенчәлеген саклап калу һәм үстерү;

5) архив һәм китапханә эше мәсьәләләре;

6) Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау мәсьәләләре;

7) халык сәнгать һөнәрчелеген һәм кәсепләрен үстерү;

8) массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эшчәнлек;

9) фән һәм фәнни эшчәнлек;

10) милли сәясәт һәм милләтара мөнәсәбәтләр;

11) милли-мәдәни оешмалар һәм дини берләшмәләр;

12) комитет каравына кертелгән башка мәсьәләләр.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 20 сентябре
№ 12-VI ДС